**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

29.08.2022 | г.Казань | № 376

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февраленнән 78 номерлы «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февраленнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 175 номерлы карарын кабул итүгә бәйле рәвештә

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февраленнән 78 номерлы «Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 7 июленнән 199 номерлы, 2021 елның 2 мартыннан 63 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә тәкъдим итәргә

«2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, 2007 елның 4 декабреннән 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июленнән 315 номерлы « Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы мәсьәләләре» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августыннан

681 номерлы «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» карары нигезендә боерам»;

Күрсәтелгән боерык нигезендә расланган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә тәкъдим итәргә (теркәлә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары И.З. Садриевка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2020 елның 21 февраленнән 78 номерлы боерыгы
(Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2022 елның 29 августыннан 376 номерлы боерыгы редакциясендә) белән расланды

# Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартларын билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр булып 1996 елның 12 гыйнварыннан 7-ФЗ номерлы «Коммерциячел булмаган оешмалар турында» федераль законның 2 маддәсендәге $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар, коммерциячел булмаган оешмалар) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә профильләштерү (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган уздырган мөрәҗәгать итүченең анкеталаштыру нәтиҗәсендә ачыкланган билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы.

2.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮ нең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында Бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә.

2.3.2. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турындагы Бәяләмә әлеге Регламентка 2 нче номерлы кушымта нигезендә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә әлеге Регламентка 3 нче номерлы кушымта нигезендә рәсмиләштерелә.

Бәяләмә һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы дәлилләнгән хәбәрнамә Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе реестр язмасы булып тормый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә алуның ул сайлаган ысулы нигезендә бирелә (җибәрелә):

язма формада гариза бирүчегә шәхсән тапшырыла яки почта аша;

электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.4. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен электрон документ яки электрон документ нөсхәсе рәвешендә кәгазьдә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә алу өчен мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы.

Гариза һәм бәяләмә бирү турында документлар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә.

Әгәр Министрлык тарафыннан Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручы оешма итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 6 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварыннан 89 номерлы карары нигезендә сораулар җибәрелгән очракта күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 15 эш көненнән дә артыкка түгел.

Әлеге карарны кабул итү вакытын озайту турында Министрлык гариза бирүчегә бәяләмә бирү турында гариза килгән көннән башлап 5 эш көне эчендә хәбәр итә.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын (электрон почта, почта аша заказлы хат белән, шәхсән, Республика порталы аша) кулланып юллау бәяләмәгә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында

дәлилләнгән хәбәрнамәгә Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) кул куйган көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Республика порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза:

билгеләнгән форма буенча кәгазьдә документ рәвешендә (әлеге Регламентка 1 нче номерлы кушымта);

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән тутырыла);

2.6.2. оештыру документларының күчермәләре;

2.6.3.гариза бирүченең яки гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ (Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткән очракта бирелә). Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне раслаучы документтан белешмәләр, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасындагы ( ИАБС) хисап язмасын раслаганда тикшерелә;

документлар гариза бирүченең вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, аның мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәлләрне тормышка ашыру өчен кирәкле булган вәкаләтләрен раслый торган ышаныч кәгазе.

Гариза бирүче күрсәтелә торган хезмәт күрсәтүләрнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына туры килүен нигезләүче документларны (белешмәләр, характеристика, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) беркетә ала.

Мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүен нигезли торган өстәмә документлар тапшыру таләп ителми.

2.6.4. Гариза һәм аңа беркетелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән тапшырылырга яисә почта аша юлланырга мөмкин.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп имзаланган (расланган) электрон документ рәвешендә Республика порталы аша тапшырылырга (юлланырга) мөмкин.

Гаризаны Республика порталы аша юллаганда, мөрәҗәгать итүче аны гади электрон имзасы белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ИАБС да теркәлү (аутентификация) процедурасын үтәргә, шулай ук хисап язмасын стандарттан түбән булмаган дәрәҗәгә расларга кирәк.

Гаризага беркетелгән электрон документлар (документларның электрон образлары), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Тапшырыла торган электрон документларның (документларның электрон образларының) сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлык тарафыннан 2013 елның 5 апреленнән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында оешманың хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын, гариза бирүче документлар тапшырган айның беренче көненә әлеге иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләр реестрына гариза бирүче турында язу кертү фактын раслаучы документлар сорала.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләре булган документларны, шул исәптән мөмкинлеге булганда – электрон формада тапшырырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәп булып тормый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итмәү өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеге тәкъдим ителгән;

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре (гаризаны электрон формада биргәндә) нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) тапшыру.

2.8. Дәүләт хезмәтен туктатып тору яки күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән аның эчтәлегенә (хезмәт күрсәтүнең күләме, сроклары, сыйфаты) карата таләпләргә туры килмәве;

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул

исәптән һөнәри белем бирү, тиешле өлкәдә эшләү тәҗрибәсе) булмавы, кирәкле квалификациясе булган затларның саны җитмәү;

в) суд, дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезләнгән дип табылган, аның гамәлләренә (гамәл кылмавы) һәм (яки) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү белән бәйле оешманың карарына бәяләмә бирү алдыннан ике ел эчендә шикаять булу;

г) оешма турында мәгълүматның ачыклык дәрәҗәсенә һәм һәркем алырлык булуының Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булганда) туры килмәү;

д) 2013 елның 5 апреленнән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товар, эш, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында оешма турында бәяләмә бирер алдыннан ике ел дәвамында мәгълүмат булу;

е) дөрес булмаган мәгълүматлар булган документлар бирү яисә документларны тиешле дәрәҗәдә әзерләп тапшырмау.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр законда каралмаган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта максималь көтү срогы.

2.10.1. Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алуны көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында соравын теркәү вакыты.

2.11.1. Гаризаны Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта аша теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән гаризаның җибәрелүен раслаучы хәбәрнамә ала.

2.11.2. Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә гариза бирелгән көнне вәкаләтле вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан теркәлү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән расписка бирә.

2.11.3. Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән гариза икенче ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бинада һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа бмәгълүматлары мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуын истә тотып урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларның (кресло-коляска һәм озатып йөрүче этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында аларга түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) объектка (бинага, бүлмәгә), шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлар (биналар, бүлмәләр) урнашкан территория буенча, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә, мөстәкыйль хәрәкәт итү, шулай ук бина һәм бүлмәләргә керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

в) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылуга ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

г) инвалидларның бинага, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;

д) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билге һәм Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган башка текст һәм график мәгълүматны кабатлау;

е) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт бирү;

6) озатып йөрүче этне махсус укытуны раслый торган һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июненнән 386н номерлы «Озатып йөри торган этне махсус укытуны раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документы булганда дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга (бина, бүлмәләргә) кертү;

7) Министрлык хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки капиталь ремонт, реконструкцияләү, модернизацияләү үткән объектларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- документларны кабул итү, бирү алып барыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

- мәгълүмати стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки капиталь ремонт, реконструкцияләү, модернизацияләү үткән объектларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

- биналарның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге зонасында урнашкан;

- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналардан инвалидлар өчен файдалана алу мөмкинлеге;

- белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;

- мәгълүмати стендларда, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

- гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

- гариза бирүче гариза һәм электрон документлар формасындагы документларын Республика порталы аша тапшырганда, хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен Республика порталында шәхси кабинет аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

- учреждение хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документлар кабул итү һәм карау вакытларын саклау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытын саклау;

3) Министрлык хезмәткәрләренең әлеге Регламентны бозуларына прецедентларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Министрлык хезмәткәрләре белән үзара тәэсир итешүе саны:

- дәүләт хезмәте күрсәт өчен кирәкле документларны биргәндә - бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша юллаганда – үзара тәэсир итешү булмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык белгече белән бер үзара хезмәттәшлегенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә Республика порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә

хокуклы.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru), Республика порталында шәхси кабинетында, Министрлыкта алырга мөмкин.

2.13.4. Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау (запрос) буенча күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә, шул исәптән күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алып, башка таләпләр һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1 Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә, аңа консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. КФҮтә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүче электрон формада түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

2) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган башка документларны, шул исәптән электрон рәвешләре 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)16 маддәсендәге 1 өлешенең 72 пункты белән билгеләнгән документлар һәм мәгълүмат, 2010 елның 27 июненнән 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 маддәсендәге 1 өлешенең 72 пункты нигезендә элегрәк расланган документлар һәм мәгълүмат бирергә;

3) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның үтәлеше барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

6) Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауларына) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итүче Республика порталы, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

2.14.5. Гаризаны формалаштыру, башка нинди дә булса формада өстәмә гариза бирү зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән башкарыла.

2.14.6. Гариза тутырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документларны күчереп алу һәм саклау мөмкинлеге;

2) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) кулланучының теләге буенча теләсә кайсы вакытта, шул исәптән гаризаның

электрон формасына зурлыкларны керткәндә хаталар килеп чыкканда һәм кабат кертү өчен кире кайтканда, гаризаның электрон формасына элегрәк кертелгән зурлыкларны саклау;

4) ИАБС да урнаштырылган мәгълүматлардан идентификацияләү һәм аутенфикацияләүнең бердәм системасында булмаган белешмәләргә кагылган өлештә Республика порталында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, мөрәҗәгать итүченең мәгълүматларын кертү алдыннан гаризаның электрон формасы кырларын тутыру;

5) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, гаризаның электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кире кайту мөмкинлеге;

6) мөрәҗәгать итүченең элек бирелгән гаризаларына бер елдан да ким булмаган вакыт эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризаларына – кимендә 3 ай эчендә керү мөмкинлеге.

2.14.7. Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакытлыча интервал дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәк булган мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, шул исәптән гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү буенча ярдәм күрсәтү;

2) мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документлар комплектын кабул итү, карау һәм башкаруга юллау;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сораулар формалаштыру һәм юллау;

4) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү һәм бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә формалаштыру һәм юллау;

5) техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлкәсендә.

3.2.1 Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате административ процедураны башкаруны башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Министрлыкка мөрәҗәгать иткән чакта административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып халыкка физик тәрбия бирү һәм физкультура – сәламәтләндерү эше бүлеге белгече (алга таба – Бүлек белгече) тора.

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта (шул исәптән электрон почта) аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Министрлык сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе һәм вакытлары, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы һәм дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле гаризаны тутыру өлешендә консультация бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәләре: консультация, тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутыру өлешендә искәрмәләр, гражданнар мөрәҗәгатен теркәү журналында консультация бирү (гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү) турында язу.

3.3. Гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар комплектын кабул итү, гаризаны теркәү һәм үтәүгә юллау.

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны электрон формада Республика порталы аша кабул итү.

3.3.1.1. Гариза бирүче электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

- авторизацияләүне башкара;
- электрон гариза формасын ача;
- дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра (кирәк булганда);
- электрон формадагы документларны яки электрон документлар образларын электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);
- электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билгене куя);
- хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билгене куя);
- тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);
- электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.4 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә нигезендә имзалана;
- электрон гариза җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Формалаштырылган гаризаны формат-мантыйкый яктан тикшерү гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр юл тутырылганнан соң башкарыла. Гаризаның электрон формасындагы дөрес тутырылмаган юл булу ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында электрон формада турыдан-туры хәбәр итү юлы аша хәбәр бирелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек итү юлы белән Министрлыкка юлланган электрон эш.

3.3.2. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.2.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) шәхсән Министрлыкның чараларны координацияләү, контроль һәм корпоратив идарә итү бүлегнә (алга таба – Оештыру бүлеге) гариза тапшыра.

Гариза почта аша заказлы почта юлламасы рәвешендә юлланырга мөмкин.

Электрон почта аша юллана торган гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзалана (раслана) һәм электрон хәбәр йөртүчеләр һәм (яки) гомумкулланылыштагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләрне, шул исәптән «Интернет» челтәрен кулланып юллана.

Почта аша заказлы почта юлламасы яки электрон формада тәкъдим ителгән гариза гомуми тәртиптә карала.

3.3.2.2. Оештыру бүлеге белгече:

законлы вәкил яисә дәүләти хезмәтен алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат сыйфатында чыгыш ясаучы гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның барлыгын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында була.

Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән мөрәҗәгать иткән чакта, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләре булган очракта, Оештыру бүлеге белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә) документлар кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр барлыгы турында хәбәр итә һәм аңа баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып документларны кире кайтара. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча (аның вәкиле) баш тарту язма рәвештә рәсмиләштерелә.

Гариза бирүче (аны вәкиле) гариза һәм документларны почта (электрон почта) аша юллаган чакта Оештыру бүлеге белгече аңа хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып торган сәбәпләрне язмача аңлатып документларны почта (электрон почта) аша җибәрә.

Документларны кабул итү өчен нигезләр булмаган очракта Оештыру бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) почта яисә электрон почта (аның теләге нигезендә) аша документлар кабул итү датасы һәм вакыты, аңа бирелгән номер белән гариза күчермәсен юллый.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша гаризаны электрон формада министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм министрга карау өчен җибәрелгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен министр урынбасарына юлланган гариза.

3.3.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына юлланган гариза.

3.3.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны башкару өчен Бүлек белгеченә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) элеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны (документлар) тапшырмаган очракта, Бүлек белгече бу Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән документ нигезендә мәгълүмат алу өчен дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрос җибәрә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан бирле бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек процессында катнашучы органнар әлеге Регламентның 2.6.5 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне (документларны) законда билгеләнгән срокта җибәрәләр.

Процедура нәтиҗәсе: запросларга җаваплар яки соралган мәгълүматларның (документлар) юклыгы турында хәбәрнамәләр.

3.4.3. Бәяләмә бирү турында Министрлыкка гариза кергән очракта һәм шул ук вакытта җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августыннан 681 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмә буенча, берничә башкарма хакимият органы, шул исәптән Министрлык белән дә гамәлгә ашырылса, Бәяләмәне Министрлык бирә. Министрлык, кирәк булганда, белешмәләрне ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә бүтән кызыксынган органнардан, шулай ук башка дәүләт хакимияте органнарыннан соратып ала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура вазыйфаи затка башкару өчен гариза кергәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: запрослар формалаштыру һәм җибәрү, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка оешмалардан ведомствоара запроска җавап буларак алар карамагында булган мәгълүматлар килү.

3.5. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү һәм бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә бирү.

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 – 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр нигезендә алынган һәм мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан

тапшырылган документлар нигезендә тапшыру хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын әзерли һәм аларны килештерүгә Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, запросларга җаваплар килгән көннән алып, ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә юлланган тапшыру хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.2. Бүлек башлыгы тапшыру хаты, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын тикшерә һәм аларны килештерүгә министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен бүлеге башлыгына кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасарына килештерүгә юлланган тапшыру хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.3. Министр урынбасары тапшыру хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектларын килештерә һәм аларны министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура килештерү өчен әлеге проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән һәм министрга карау өчен җибәрелгән тапшыру хаты, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә проектлары.

3.5.4. Министр бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән тапшыру хатына кул куя.

Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән имзаланган тапшыру хаты Оештыру бүлегенә җибәрелә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәү өчен оештыру бүлегенә министр тапшырган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән тапшыру хаты.

3.5.5. Оештыру бүлеге белгече:

бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә белән тапшыру хатын терки һәм дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән имзаланган бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) бирүне гамәлгә ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура:

бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) почта аша җибәргәндә – бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) Министр тарафыннан имзаланганнан соң бер эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә) шәхсән алу турында күрсәтелгәндә – гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: әлеге Регламентның 2 нче номерлы кушымтасы

нигезендәге форма буенча бәяләмә яки әлеге Регламентның 3 нче номерлы кушымтасы нигезендә бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамә бирү (юллау).

3.5.6. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу өчен Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, мөрәҗәгать итүчегә шәхси кабинетына автомат рәвештә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон образы җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны имзалаган көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Республика порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ юллау (бирү).

3.6. Техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хатаны) (алга таба – техник хата) төзәтү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Министрлыкка түбәндәгеләрне юллый:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);
- дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;
- юридик көчкә ия, техник хата булуын раслаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан түбәндәге ысуллар белән: Министрлыкка шәхсән, почта (шул исәптән электрон почта) аша яисә Республика порталы аша бирелә.

3.6.2. Оештыру секторы белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм кушылып бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм гаризаны министрга юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга юлланган гариза тора.

3.6.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министр урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: карау өчен министр урынбасарына юлланган гариза.

3.6.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карау өчен юлланган гариза.

3.6.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны башкару өчен Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза Бүлеккә җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: башкару өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.6.6. Бүлек белгече документларны карый һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны, мөрәҗәгать итүчедән (вәкилдән) техник хата булган документның оригиналын алып, шәхсән имза куеп мөрәҗәгать итүчегә (вәкилгә) тапшыра, яки мөрәҗәгать итүчегә почта аша (электрон почта аша) техник хата булган документның төп нөсхәсен Министрлыкка тапшырганда документ алу мөмкинлеге турында хат юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар Бүлек белгеченә башкару өчен гариза юлланганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламент үтәлешен тикшерү формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә Гариза бирүчеләрнең (аның вәкиле) хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләр карауны, тикшерүләр уздыру, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләр (аның вәкиле) мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамьсезлекләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларның үтәлешен саклауны тикшерү формалары булып түбәндәгеләр тора:

- эш башкаруны алып бару;
- документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;
- документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклау;
- дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәү.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедуралар үтәлешен тикшерүне тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә (справка) бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләр эзлеклелеген саклауны агымдагы тикшерү министр урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозган очраклар ачыкланган вакытта гаепле затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү

процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) караунның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлекләренә) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләрнең Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр Министрлыкка дәгъва бирү хокукы бар.

Министрның карарлары, дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны (запрос) теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында бирү яки гамәлләр кылу каралмаган документлар яки мәгълүматлар бирүне яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп итү;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктату өчен сәбәпләр федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 маддәсе 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул иткәндә беренчел кире кагу вакытында аларның булмавы яисә дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар

һәм мәгълүмат таләп итү.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталы, Республика порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаять кергәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органга, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи затына гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән язудагы һәм басмадагы хаталарны төзәтүдән баш тартуга карата шикаять белдергән очракта яисә мондый төр төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның исеме, фамилиясе, атасының исеме (булган очракта), тору урыны турында белешмә, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлекләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) белән килешмәгән дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буларак түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда язуда һәм басмада җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән алу каралмаган акчалата чараларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формаларда;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яисә гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап юллана.

5.6. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип таныган очракта, гариза бирүчегә адресланган җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта ачыкланган бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка

ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлык өчен гафу үтенелә һәм алга таба дәүләт хезмәтен алу максатында гариза бирүчегә башкарырга кирәк булган эш-гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә, җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, нигезләнгән аңлатма, шулай ук әлеге карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау дәвамында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат булган барлык материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче номерлы кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
спорт министрына

_______________________________
(фамилия, инициаллары)
_______________________________
_______________________________
(оешма атамасы, адресы
(почта һәм (яки) электрон),
телефон номеры (булганда)

ГАРИЗА

Сездән _____________________________________________ социаль
(социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешма атамасы)
юнәлешле коммерциячел булмаган оешма күрсәтә торган җәмгыятькә файдалы
_______________________________________________________________________
(җәмгыятькә файдалы хезмәт атамасы)
хезмәтләр сыйфатының аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүегезне сорыйм.

Оешманың чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциячел булмаган оешма түгеллеген һәм аның бер ел һәм аннан да күбрәк вакыт дәвамында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябреннән 1096 номерлы «Җәмгыятькә файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтү күрсәтүен раслыйбыз:
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
_______________________________________________________________________
(җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүнең Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән аның эчтәлегенә (тапшыру күләме, сроклары, сыйфаты) куелган таләпләргә туры килүен раслау);

(җәмгыятькә файдалы хезмәтләрне башкаруда турыдан-туры катнашкан затларның (шул исәптән оешма хезмәткәрләренең һәм граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеме, әлеге өлкәдә эшләү тәҗрибәсе), андый затларның саны җитәрлек булуын раслау)

(җәмгыятькә файдалы хезмәтләр алучыларның аларны күрсәтү сыйфаты белән канәгать булуын раслау (гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау һәм (яки) җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле оешманың суд, дәүләт күзәтүе (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, аларның компетенциясе нигезендә, бәяләмә биргәнче 2 ел эчендә башка органнар тарафыннан нигезләнгән карарлар булмау)

(коммерциячел булмаган оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм мөмкинлеген раслау)

(оешманың 2013 елның 5 апреленнән 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эш, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслау)

Раслаучы документлар теркәлә:

1. ____________________
2. ____________________
3. ____________________

һәм башкалар.

(Вазыйфасы) (Имза) (Ф.И.Аи.)

«__» _______ 20__ ел

М.У. (булганда)

Социаль юнәлешле коммерциячел
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы
хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга
туры килү-килмәве турында бәяләмәләр
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче номерлы кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

(Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бланкы)
(форма Кагыйдәләргә 2 нче номерлы кушымтада китерелгән)

Кемгә: ________________________
________________________________
Элемтә мәгълүматлары: ___________
________________________________
Вәкил: ________________
________________________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
________________________________

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма
күрсәтә торган җәмгыятькә файдалы хезмәтләрнең
сыйфаты билгеләнгән критерийларга туры килүе турында
БӘЯЛӘМӘ

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы ______________________________
___________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциячел оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәве номеры)

______ ел дәвамында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 27 октябрендәге «Җәмгыятькә файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 1096 номерлы карары белән расланган җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган түбәндәге җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүен раслый:
___________________________________________________________________________;
___________________________________________________________________________;
___________________________________________________________________________.
(җәмгыятькә файдалы хезмәтләр атамалары)

Татарстан Республики
Спорт министры

М.У. ________ ________ ________
(Дата) (Имза) (ФИАи)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче номерлы кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

*(Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган бланкы)*

Кемгә: ___________________________
___________________________________
Элемтә мәгълүматлары: ____________
___________________________________
Вәкил: __________________
___________________________________
Вәкилнең контакт мәгълүматлары:
___________________________________

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма күрсәтә торган җәмгыятькә файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту хакында дәлилләнгән хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәве номеры)
күрсәтә торган түбәндәге җәмгыятькә файдалы хезмәтләрнең:
__________________________________________________________________________;
__________________________________________________________________________;
__________________________________________________________________________.
(җәмгыятькә файдалы хезмәтләр атамалары)
сыйфаты туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Җәмгыятькә файдалы әлеге хезмәтләр җәмгыятькә файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәгеләр сәбәпләр буенча туры килми:

______________________________________________________________________________;
______________________________________________________________________________;
______________________________________________________________________________.

(критерийларга туры килмәү күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Спорт министры

| | | | |
|---|---|---|---|
| М.У. | ____________ | ____________ | ________________ |
| | (Дата) | (Имза) | (ФИАи) |

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
4 нче номерлы кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы
Спорт министрына
______________________________
(фамилия, инициаллар)
______________________________
______________________________
(оешма атамасы, адрес
(почта һәм (яки) электрон),
телефон номеры (булганда)

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

_______________________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма атамасы)

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган җәмгыятькә файдалы хезмәт күрсәтүнең билгеләнгән критерийларга туры килүе яки социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтнең билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында бәяләмә биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итә.

__________________________________________________________________ язылган:

(бирелгән документ)

_______________________________________________________________________________,

Дөрес мәгълүматлар: _____________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйбыз.

Кабат рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хәбәрнамәне) гаризаны карау нәтиҗәләре буенча:

_______________________________________________________________________________

(шәхсән, почта буенча)

бирүегезне сорыйбыз.

Түбәндәге документларны теркибез:

1. ______________________________
2. ______________________________

______________________________________________

(Вазыйфа) (Имза) (Ф.И.Аи.)

«___» _________20 ___ел

М.У. (булганда)

\

Социаль юнәлешле коммерциячел
булмаган оешмалар тарафыннан
күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы
хезмәтләрнең билгеләнгән критерийларга
туры килү-килмәве турында бәяләмәләр
бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
кушымта (белешмә)

Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган
җәмгыятькә файдалы хезмәтләр сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирү һәм аны
бирүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 222 81 02 | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 222 81 07 | Ildar.Sadriev@tatar.ru |
| Чараларны координацияләү, тикшерү һәм корпоратив идарә бүлеге башлыгы | (843) 222 81 18 | Y.Semenova@tatar.ru |
| Халыкка физик тәрбия бирү һәм физкультура-сәламәтләндерү эше бүлеге башлыгы | (843) 222 81 45 | Dmitriy.Dorogov@tatar.ru |
| Халыкка физик тәрбия бирү һәм физкультура-сәламәтләндерү эшләре бүлегенең әйдәп баручы консультанты | (843) 222 81 62 | Rafina.Ahmetzyanova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы | (843) 264 77 84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |